**III ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨГЕЛМӘ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

**ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ СЕССИЯ**

**6нчы КАРАР**

Бөгелмә шәһәре 20 сентябрь, 2019 ел

**Бөгелмә шәһәре Советы**
**Сессиясе карарларының**
**үз көчен югалтуын тану турында**

Законнарга һәм хокукый-норматив актларга туры китерү максатында,

**Бөгелмә шәһәр Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
   - Бөгелмә шәһәр Советының 2014 елның 27 февралендә булып узган XXXIV сессиясенең "Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәр е муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфадагы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт вазыйфаларына бәйле рәвештә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгәндә бүләк алуы турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу), аны сатканнан кергән средстволарны исәпләү тәртибе турында"гы 5нче карарын»;
   - Бөгелмә шәһәр Советының 2019 елның 17 апрелендә булып узган XXIII сессиясенең "Бөгелмә шәһәр Советының 2014 елның 27 февралендә булып узган XXXIV сессиясенең "Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфадагы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт вазыйфалар ына бәйле рәвештә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгәндә бүләк алуы турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу), аны сатканнан кергән средстволарны исәпләү тәртибе турында"гы 5нче карарына үзгәрешләр кертү турында"гы 13нче карарын.
2. Әлеге карар күмәк мәгълүмат чараларында рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калддырам.

**Бөгелмә шәһәре мэры урынбасары И.Б. Белова**